# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында” Татарстан Республикасы Законының 2 һәм 8 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 26 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында” 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяга түбәндәге эчтәлекле $7^{1}$ пункт өстәргә:

“$7^{1)}$ хосусыйлаштырылганда электр челтәре хуҗалыклары объектларына, җылылык энергиясе чыганакларына, җылылык челтәрләренә, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларына һәм мондый системаларның аерым объектларына салынган эксплуатация йөкләмәләре шартларының үтәлешен тикшереп тору тәртибен билгели;”;

2) 8 статьяның 2 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

дәүләт мөлкәтенең исеме һәм аны индивидуальләштерергә мөмкинлек бирә торган башка мәгълүматлар (мөлкәткә характеристика);

дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру алымы;

мөлкәтнең башлангыч бәясе;

кичектереп түләү срогы (бирелгән очракта);

дәүләт мөлкәтен бәяләү нәтиҗәләре;

дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру өчен кирәкле башка белешмәләр.

Унитар предприятиенең мөлкәт комплексын хосусыйлаштыру очрагында дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарда шулай ук түбәндәгеләр дә раслана:

унитар предприятиенең хосусыйлаштырылырга тиешле мөлкәт комплексы составы;

унитар предприятиенең мөлкәт комплексы составында хосусыйлаштырылырга тиеш булмаган объектлар исемлеге (шул исәптән чыгарылма хокуклар);

унитар предприятиене үзгәртеп кору юлы белән төзелә торган ачык акционер җәмгыятьнең яисә җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең устав капиталы күләме;

ачык акционер җәмгыять акцияләренең саны, категориясе һәм номиналь бәясе яисә Татарстан Республикасы өлешенең номиналь бәясе.

Электр челтәре хуҗалыклары объектларын, җылылык энергиясе чыганакларын, җылылык челтәрләрен, кайнар су белән тәэмин итүнең үзәкләштерелгән системаларын һәм мондый системаларның аерым объектларын хосусыйлаштырган очракта, хосусыйлаштыру турындагы карар составына “Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның $30^1$ статьясы нигезендә рәсмиләштерелгән инвестиция һәм эксплуатация шартлары кертелергә тиеш.

Унитар предприятиенең мөлкәт комплексы составында хосусыйлаштырылырга тиеш булмаган объектлар (шул исәптән чыгарылма хокуклар) башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан алына.

Дәүләт предприятиесе ачык акционер җәмгыять итеп үзгәртелгән очракта, башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы мондый предприятиене хосусыйлаштыру планын төзү турында карар кабул итәргә мөмкин. Хосусыйлаштыру планы рәвеше башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан раслана.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 20 гыйнвары
№ 8-ТРЗ